| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2025 г. Казань № 341-40/тэ-2025

«РЖД» ААҖ филиалы – Җылылык-су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциясенең структур бүлекчәсе – Җылылык-су белән тәэмин итү буенча Куйбышев дирекциясенең Ульяновск территориаль участогы тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.11.2021 ел, №305-54/тэ-2021 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2026 ел өчен төзәтмә кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 03.12.2025 ел, № 29-ПР беркетмәсе нигезендә һәм 2026 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2026 елга җылылык энергиясенә (егәрлегенә) озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «РЖД» ААҖ филиалы – Җылылык-су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциясенең структур бүлекчәсе – Җылылык-су белән тәэмин итү буенча Куйбышев дирекциясенең Ульяновск территориаль участогы тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «РЖД» ААҖ филиалы – Җылылык-су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциясенең структур бүлекчәсе – Җылылык-су белән тәэмин итү буенча Куйбышев дирекциясенең Ульяновск

территориаль участогы тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2022-2026 елларга тарифлар билгеләү турында» 17.11.2021 ел, №305-54/тэ-2021 карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.11.2022 ел, №446-35/тэ-2022, 08.12.2023 ел, №453-41/тэ-2023, 12.12.2024 ел, № 388-33/тэ-2024 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән билгеләнгән тарифларга 2026 ел өчен төзәтмә кертеп, 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымтада) бирергә.

2. Әлеге карарның 1 пункты белән төзәтелгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.11.2021 № 305-54/тэ-2021 карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 03.12.2025 № 341-40/тэ-2025 карары редакциясендә)

## «РЖД» ААҖ филиалы – Җылылык-су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциясенең структур бүлекчәсе – Җылылык-су белән тәэмин итү буенча Куйбышев дирекциясенең Ульяновск территориаль участогы тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2022-2026 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Кискен һәм редукциял әнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Тукай муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «РЖД» ААҖ филиалы – Җылылык-су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Җылылык-су белән тәэмин итү буенча Куйбышев дирекциясенең Ульяновск территориаль участогы | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1 643,93 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1 730,51 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1 809,78 <*> | - | - | - | - | - |
| | | 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр | 1 809,78 | - | - | - | - | - |
| | | 2024 елның 1 июленнән 2024 елның 31 декабренә | 1 993,40 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кадәр | | | | | | |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 1 993,40 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 2 270,21 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 2 270,21 | - | - | - | - | - |
| | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 2 573,91 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән) <**> | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1 972,72 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 2 076,61 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 2 171,74 <*> | - | - | - | - | - |
| | | 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр | 2 171,74 | - | - | - | - | - |
| | | 2024 елның 1 июленнән 2024 елның 31 декабренә кадәр | 2 392,08 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 2 392,08 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 2 724,25 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 2 769,66 | - | - | - | - | - |
| | | 01.10.2026 | 3 140,17 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | башлап 31.12.2026 кадәр | | | | | | | |

<*> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.
<**> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге